## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**28 ноябрь, 2025 ел** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елнын 28 июлендәге 45- ТЗР номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 25 нчы ноябрендә 18 сәг 00 минутта, 2025 елның 26 нчы ноябрендә 18 сәг 00 минутта, 2025 елның 27 нче ноябрендә 18 сәг 00 минутта, 2025 елның 28 нче ноябрендә 18 сәг 00 минутта, булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән "2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Федоровский торак пункты территориясендә гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү( шул исәптән җәйге вакытта авыл территориясен чабу) ;
- ремонт коймаларны кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү
- су белән тәэмин итү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү челтәрләрен , аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- җирлекнең торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 372 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -193, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 193 катнашучы тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең Федоровский авылында гражданнар жыенын узган дип, гражданнар жыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Федоровский торак пункты территориясендә һәм аларның гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү( шул исәптән җәйге вакытта авыл территориясен чабу) ;

- ремонт коймаларны кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү

-су белән тәэмин итү системаларын, су жыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү челтәрләрен, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- җирлекнең торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланырга рөхсәт итәргә.»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар жыенында рәислек иткән,
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Зәйнуллин